КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 7 декабрь г.Казань № 1299

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының торак-коммуналь өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле механизмнарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 11 сентябрь, 858 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының торак-коммуналь өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле механизмнарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының торак-коммуналь өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле механизмнарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 11 сентябрь, 858 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 5 октябрь, 1072 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының торак-коммуналь өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле механизмнарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага

Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

8 пунктның өченче абзацында «30 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «5 нче календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктта:

беренче абзацта «сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштырылган көннән соң килүче көннән алып 30 календарь көн эчендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучы җитәкче (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан имзаланган, сайлап алуда катнашу турында ирекле рәвештә язылган, әлеге Тәртипнең 26 пунктында күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе турында белешмәләрне үз эченә алган хат;»;

13 пунктта:

икенче абзацта «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштырылган көннән соң килүче көннән алып 30 календарь көн эчендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «өч эш көне» сүзләрен «бер эш көне» сүзләренә алыштырырга;

23 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин